**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№962**
**11.02.2025**

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары укучылары арасында «СОзнание» шәһәр конкурсын оештыру һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5186 номерлы Карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсенә Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары укучылары арасында «СОзнание» шәһәр конкурсын (алга таба - конкурс) 2025 елның мартында оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны үткәрүгә чыгымнарны финанслауны 2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлеге буенча каралган акчалар хисабына 30 000,00 (утыз мең) сум 00 тиен күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 11 февралендәге
962 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
һөнәри белем бирү оешмалары
һәм югары белем бирү оешмалары укучылары арасында
«СОзнание» шәһәр конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары укучылары арасында «СОзнание» шәһәр конкурсын (алга таба - конкурс) оештыру һәм үткәрү тәртибен, срокларын, катнашучыларга карата таләпләрне билгели.

2 бүлек. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2. Конкурсның максаты булып студент отрядларының традицияләрен саклау һәм арттыру, патриотик тәрбия бирү һәм студент яшьләрнең социаль-шәхес компетенцияләрен үстерү.

3. Конкурсның бурычлары:

1) яшьләрне студент отрядлары эшчәнлегенә җәлеп итү, аларның хезмәт, социаль активлыгын мотивацияләү;

2) сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

3) студент отрядлары хәрәкәтенең уңай имиджын ныгыту;

4) катнашучыларның иҗади потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру.

3 бүлек. Конкурсны оештыручылар

4. Конкурсны оештыручылар булып тора: Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Яр Чаллы студент хезмәт отрядлары үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе (алга таба - «НЦСТО» МАУ)

5. Конкурсны үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты оештыру, мәгълүмати һәм координацияләү функцияләрен башкара.

4 бүлек. Конкурсны үткәрү сроклары һәм тәртибе

6. Конкурс 2025 елның мартында график нигезендә үткәрелә, ул өстәмә рәвештә алынган заякаларга җавап итеп җибәреләчәк.

7. Конкурста катнашу өчен 2025 елның 1 мартына кадәр sto-chelny@mail.ru электрон почтасына заявка җибәрергә кирәк (әлеге нигезләмәгә кушымта).

8. Заявкалар җитәрлек күләмдә булмаса, конкурсның Оештыру комитеты заявкаларны кабул итү срогын озайту хокукына ия.

5 бүлек. Конкурста катнашучылар

9. Конкурста Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары

белем бирү оешмаларының командалары катнаша.

10. Команда составы – 6 кеше.

11. Бер белем бирү оешмасыннан бер генә заявка бирелергә мөмкин.

## 6 бүлек. Конкурсның этаплары

12. «Квиз» – катнашучылар үз белемнәрен күрсәтә торган интеллектуаль уен. Һәрбер дөрес җавап өчен команда балл ала. Интеллектуаль уен нәтиҗәләре буенча урыннар җыелган баллар нигезендә бүленә.

13. «Лазертаг» – команда хәрби-тактик уен. Хәрби-тактик уен нәтиҗәләре буенча урыннар турнир челтәре буенча командалар арасында матчлар сериясендә яуланган җиңүләр саны нигезендә бүленә.

14. «Шпион» - спорт ярышлары элементлары булган интерактив квест-уен. Интерактив квест-уен нәтиҗәләре буенча урыннар маршрут узу вакыты нигезендә бүленә.

## 7 бүлек. Конкурска йомгак ясау

15. Конкурс йомгаклары буенча оештыру комитеты җыелган баллар суммасы буенча конкурс җиңүчесен (беренче урынны алган команда) һәм призерларны (икенче һәм өченче урыннарны алган командалар) билгели. Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

16. Баллар конкурсның һәр этабы нәтиҗәләре буенча командалар тарафыннан яулаган урыннар нигезендә, таблицада каралганча бүленә:

| Урын | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | ≥11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Баллар | 10 | 9 | 8 | 7 | 6 | 5 | 4 | 3 | 2 | 1 | 0 |

17. Җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү конкурсның йомгаклау этабында була. Конкурс җиңүчеләре һәм призерлары кыйммәтле бүләкләр һәм дипломнар белән бүләкләнә.

## 8 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре

18. Әлеге нигезләмәдә чагылдырылмаган барлык мәсьәләләр конкурсның оештыру комитеты тарафыннан, килеп туган хәл кысаларында үз компетентлыгыннан чыгып һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә хәл ителә.

19. Конкурсның оештыру комитеты конкурс этапларына һәм аларны үткәрү даталарына үзгәрешләр кертергә хокуклы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәренең һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары укучылары арасында «СОзнание» шәһәр конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
кушымта

___________________ __________________________________ командасыннан
(белем бирү оешмасының тулы исеме)

«СОзнание» шәһәр конкурсында катнашуга
заявка

| № | Катнашучының Ф.И.А.и. | Туу датасы | Элемтә телефоны номеры |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| 4. | | | |
| 5. | | | |
| 6. | | | |